БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

«22» 01 2021 ел № 33

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булып торуын һәм авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль район җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләргә.

2. Территориядә җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу системасын төзү, эзлекле камилләштерү һәм аның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү эшен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрен территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документлары проектын әзерләү буенча комиссиягә (Балтач район башкарма комитетның 2009 елның 2 июлендәге 249 номерлы карары (2020 елның 21 гыйнварындагы 34 номерлы үзгәрешләр белән)) йөкләргә.

3. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләрне башкару тәртибен һәм вакытын расларга (1 нче кушымта).

4. Кызыксынган затларның тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрен территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документлары проектын әзерләү буенча комиссиягә җибәрү тәртибен расларга (2 нче кушымта).

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетның
2021 елның 22.01
33 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләрне башкару**
**ТӘРТИБЕ ҺӘМ ВАКЫТЫ**

## 1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү этаплары

1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү.
2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләүгә техник йөкләмәне раслау.
3. Шартнамә яки муниципаль контракт төзү.
4. Техник йөкләмә нигезендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләү.
5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген контрольдә тотучы вәкаләтле зат тарафыннан проектны тикшерү.
6. Проект материалларын килештерү максатыннан территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырып чыгару.
7. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын килештерү.
8. Килешү нәтиҗәләре буенча җыелма бәяләмәне рәсмиләштерү.
9. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау тәртибе.
10. Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына торак пунктлар чикләре турында белешмәләр кертү.
11. Башкарылган эшләрне кабул итү һәм тапшыру тәртибе.

## 2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләү буенча эшләрне үткәрү тәртибе һәм вакытлары

| № т.б. | Эшләр уздыру тәртибе | Эшләрне үткәрү вакыты | Башкаручы, җаваплы зат |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү хакында хәбәрне бастырып чыгару | Карар кабул ителгәннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге |
| 2 | Проектны әзерләү өчен техник йөкләмә эшләү | 30 көн эчендә | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге |
| 3 | Шартнамә яки муниципаль контракт төзү | 60 көн эчендә | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге |
| 4 | Техник йөкләмә нигезендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын (яки үзгәрешләр кертүне) эшләү | Муниципаль контрактта күрсәтелә | Проект оешмасы, җирлек башлыгы |
| 5 | - Муниципаль районда шәһәр төзелеше эшчәнлеген контрольдә тотучы вәкаләтле зат тарафыннан проектны тикшерү<br>- Проект материалларын килештерү максатыннан территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырып чыгару<br>- Гавами тыңлаулар үткәрү | Проект башкарма комитетка кергәннән соң 60 көн эчендә | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге |
| 6 | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын (үзгәрешләр кертүне) килештерү | Проект кабул ителгәннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча | ТР Министрлар Кабинеты |

Балтач район башкарма комитетның
2021 елның 22.01.
33 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Кызыксынган затларның тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрен территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документлары проектын әзерләү буенча комиссиягә**

**ҖИБӘРҮ ТӘРТИБЕ**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү турында хәбәрне бастырылганнан соң, кызыксынган затлар, билгеләнгән вакыт эчендә,Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрен территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документлары проектын әзерләү буенча комиссиягә (алга таба – Комиссия) үз тәкъдимнәрен җибәрә алалар.
2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрен территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документлары проектын әзерләү буенча комиссиягә» дигән тамга белән тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 422250, Балтач районы, Балтач штп., Ленин урамы, 42 нче йорт .
3. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына тәкъдимнәр, кире адресын һәм тәкъдимнәр әзерләү датасын күрсәтеп, аларны бәян иткән юридик (вазыйфасы, оешманың исеме һәм җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелә) яки физик (фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелә) зат имзасына алынырга тиеш.
4. Тәкъдимнәр теләсә нинди формада (кәгазьдә, электрон чыганакларда) бирелә ала. Җибәрелгән материаллар кире кайтарылмый.
5. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертелә, анда аларга җаваплар күрсәтелә.
6. Мөрәҗәгатьләрне теркәү махсус журналда башкарыла.
7. Билгеләнгән вакыт үткәннән соң комиссиягә кергән тәкъдимнәр, имза куелмаган тәкъдимнәр, шулай ук проектны әзерләүгә катнашы булмаган тәкъдимнәр комиссия тарафыннан каралмый.